РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
АЛЬМЕТЬЕВСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«17» июня 2021 г. г. Альметьевск № 37

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының "Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре территориясендә җир салымы турында» 2013 елның 15 ноябрендәге 116 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 14 статьясы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Уставының 29 статьясы нигезендә

Әлмәт шәһәр Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының "Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре территориясендә җир салымы турында» 2013 елның 15 ноябрендәге 116 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2014 елның 2 октябрендәге 141 номерлы, 2014 елның 19 ноябрендәге 151 номерлы, 2015 елның 6 маендагы 179 номерлы, 2015 елның 20 ноябрендәге 13 номерлы, 2016 елның 8 ноябрендәге 49 номерлы, 2018 елның 31 маендагы 122 номерлы, 2018 елның 15 ноябрендәге 126 номерлы, 2019 елның 28 августындагы 166 номерлы, 2020 елның 12 мартындагы 189 номерлы, 2020 елның 28 августындагы 206 номерлы карарлар белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның 3 пунктына түбәндәге эчтәлекле җиденче һәм сигезенче абзацлар өстәргә:

«хайваннар өчен приют итеп кулланыла торган җир кишәрлекләренә карата оешмалар, учреждениеләр»;

«даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукында бирелгән җир кишәрлекләренә карата Әлмәт муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән финанслана торган бюджет оешмалары һәм учреждениеләре»;

1.2. карарның 3 пунктындагы җиденче һәм сигезенче абзацларын тугызынчы һәм унынчы абзацлар дип санарга;

1.3. карарның 4 пунктындагы дүртенче абзацын тешереп калдырырга.

2 Район Башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан

Зак. № 2624

Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда (PRAVO.TARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның 1.1 пунктындагы өченче абзацы рәсми басылып чыккан кененнән алып бер ай узгач үз кечено кере һәм 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук менәсәбәтләренә үз йогынтысын тарата. Әлеге карарның 1.1 пунктындагы икенчө абзацы һәм 2 пункты рәсми басылып чыккан көненнән үз кеченә керә һәм үз йогынтысын 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук менәсәбәтләренә тарата.

4. Әлеге карарның үтәлешөн контрольдә тотуны шәһәр Советының бюджет-финанс мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Мусин Р.Ф.).

Шәһәр Башлыгы Т.Д. Нагуманов